ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 4** **16 октябь 2020 ел**

Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлегенең Яссы-Тугай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 һәм 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Дим-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Советының 2009 елның 17 июлендәге 7 санлы карары белән кабул ителгән 4.4 бүлегенең 4 подпункты «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 ноябрендәге 15 санлы карары белән кабул ителгән» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Дим-Тамак авыл җирлеге башлыгы урынбасары К А Р А Р К А Б У Л И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Яссы-Тугай авылы, Тукай урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Яссы-Тугай авылы, Тукай урамы, 41 нче йорт адресы буенча гражданнар җыенын 2020 елның 27 октябрендә 10: 00 сәгатьтә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2019 елның 22 ноябрендәге 6 санлы «2020 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе” буенча Ютазы муниципаль районы Яссы-Тугай авыл җирлеге территориясендә балачактан инвалидлардан, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына эшкә чакырылган гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Яссы-Тугай авылы гражданнарының җыены карарын үзгәртергә сез ризамы: Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Яссы-Тугай торак пункты территориясендә балачактан инвалидлардан, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына эшкә чакырылган гражданнардан тыш яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда үзара салым кертүгә 400 сум күләмендә акча түләргә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә әлеге акчаларны юнәлдерергә:

- Яссы-Тугай авылының Татарстан урамы буенча вак таш-ком катнашмасы сатып алу, ташу һәм җәю".

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Димтамак авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Димтамак авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Ф.М.Гарипов